РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Чистопольский муниципальный район
Совхозно-Галактионовское
сельское поселение

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Чистай муниципаль районы
Галактионово совхозы
авыл жирлеге

422965 РТ Чистопольский район с.Александровка ул. Школьная 10 тел. (84342) 3-74-75

Постановление Карар

2019 елның 22 нче ноябре № 6

Чистай муниципаль районы Совхоз-Галактионово авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 23 августындагы, 10 нче номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай шәһәр прокуратурасының 2019 елның 13 ноябрендәге 02-08-02-2019 номерлы протестын карап чыкканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2-1 статьясына нигезләнеп, Совхоз-Галактионово авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Совхоз-Галактионово авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 23 августындагы 10 номерлы «Чистай муниципаль районының « Совхоз-Галактионово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр), Чистай муниципаль районының «Совхоз-Галактионово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), Чистай муниципаль районының «Совхоз-Галактионово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары (администраторлары), Чистай муниципаль районының «Совхоз-Галактионово авыл җирлеге» бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары), эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудиты чыганакларын гамәлгә ашыру Кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру» III бүлегенең 31 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31. Эчке финанс аудиты бюджет акчаларының баш администраторы җитәкчесенә, бюджет чараларын бүлүче җитәкчесенә, бюджет акчаларын алучылар җитәкчесенә, бюджет керемнәре администраторы җитәкчесенә, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторы җитәкчесенә бюджет чараларын формалаштыру һәм бирү эшчәнлегендә булып тора:

1) бюджет акчваларын бүлүченең, бюджет акчаларын алучының, бюджет керемнәре администраторының, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторының (алга таба - бюджет акчалары администраторы), бюджет акчаларының баш администраторының, бюджет акчаларының баш администраторының бюджет вәкаләтләрен үтәүне бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат, шул исәптән бюджет хисаплылыгының дөреслеге турында бәяләмә;
2) финанс менеджментының сыйфатын күтәрү, шул исәптән бюджет акчаларын кулланунық нәтиҗәлелеген арттыру турында тәкъдимнәр;
3) финанс менеджментының сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән карарларны үтәү

нәтиҗәләре турында бәяләмәләр.

Эчке финанс аудиты структур бүлекчәләр һәм (яисә) вәкаләтле вазыйфаи затлар, бюджет акчаларының баш администраторы, эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән бюджет чаралары администраторы хезмәткәрләре тарафыннан функциональ бәйсезлек нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бюджет акчалары администраторы үз карамагында булган бюджет акчаларының баш администраторына, яисә әлеге бюджет акчаларының баш администраторы карамагындагы бюджет акчаларының башка администраторына эчке финанс аудитын башкару буенча вәкаләтләрне эчке финанс аудитының федераль стандартлары нигезендә тапшырырга хокуклы.»

1.2. «Эчке финанс аудитын гамәлгә ашыру» III бүлегенең 32 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Эчке финанс аудиты түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

1) бюджет акчалары баш администраторының, бюджет акчалары администраторының хокук мөнәсәбәтләрен, бюджет вәкаләтләрен үтәүгә карата таләпләрне үтәү максатларында гамәлгә ашырыла торган эчке процессның ышанычлылыгын бәяләү (алга таба - эчке финанс контроле) һәм эчке финанс контролен оештыру турында тәкъдимнәр әзерләү;
2) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 264.1 статьясындагы 5 пункты нигезендә кабул ителгән ведомство (эчке) акты нигезендә бюджет хисабының бердәм методологиясен алып бару, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән бюджет хисабын төзү, тәкъдим итү һәм раслау тәртибенең дөреслеген һәм бюджет хисабының бердәм методологиясен алып бару тәртибенең туры килүен раслау.
3) финанс менеджментының сыйфатын күтәрү.

Бюджет вәкаләтләрен үтәү сыйфатын мониторинглауны, шулай ук активлар белән идарә итүнең сыйфатын, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны үз эченә алган финанс менеджментының сыйфатын мониторинглау түбәндәгечә уздырыла:

- финанс органы тиешле бюджет акчаларының баш администраторларына карата билгеләгән тәртиптә;
-бюджет акчаларының баш администраторы ведомство буйсынуындагы бюджет акчалары администраторларына карата билгеләгән тәртиптә.

Финанс менеджменты сыйфатын мониторинглауны уздыру тәртибе шул исәптән түбәндәгечә билгеләнә:

- финанс менеджменты сыйфаты күрсәткечләрен исәпләү һәм анализлау, күрсәтелгән мониторинг үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны формалаштыру һәм тәкъдим итү кагыйдәләре;
-финанс менеджменты сыйфатын мониторинглау нәтиҗәләре турында хисап формалаштыру һәм тапшыру кагыйдәләре.

Тиешле бюджет акчаларының баш администраторы, үзенә буйсынучы бюджет акчалары администраторларына карата финанс менеджментының сыйфатын мониторинглауны уздыру вәкаләтләрен тапшыру һәм финанс органы белән килештереп, күрсәтелгән вәкаләтләрне шушы финанс органына тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

Совхоз-Галактионово авыл җирлеге
башлыгы В.Л.Донеев